**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ _______________ ______

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 25 апрелендәге ПР-100 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 25 апрелендәге ПР-100 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 36 нчы кушымтаның 2.5 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»

1.2. 14 нче кушымтага 1 нче кушымтаның 2.5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «4) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»

1.3. 29 нчы кушымтага 1 нче кушымтаның 2.5 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «5) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;»

1.4. 34 нче кушымтага 2 нче кушымтаның «е» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «е) гражданның хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы (2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен) турында документлар, шулай ук производствода бәхетсезлек очрагын яисә һөнәри авыруны тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән документлар;»

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Л.П.Галиуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев